## Дини һәм милли тәрбия

# Татар балалары мөселманча ял иттеләр



Кинель-Черкассы мәчете

Узган елда татар милли хәрәкәте җитәкчеләре һәм мөфтият әһелләре Самар өлкәсенең мөселман балалары өчен Кызыл Яр районында урнашкан нарат урманлыгында ял оештырганнар иде. Табигать кочагында балалар ял да иттеләр, намаз укырга да өйрәнделәр, динебез Ислам таләпләрен дә үзләштерделәр. Ялдан соң, йомгаклау җыелышында әзәри, казах милли оешмаларының юлбашчылары балаларга дин сабакларын бирүгә каршы төштеләр. Быел исә, шул фикерләрне исәпкә алып, җәйләүгә бары тик татар балаларын гына җыйганнар. Татарлар белән ял итәргә биш башкорт һәм ике таҗик баласы ризалык биргәннәр.

Быелгы ялны өлкәнең Кинель-Черкассы авылы янында бик матур инеш буенда оештырганнар. Акрын агымлы Кинель елгасы, сөзәк яр битендә комлык. Балалар туйганчы су коеналар. Мөселманча. Кызлар коенып туйгач, малайлар суга төшә.

Атналык менюларын карадым. Ризыклар төрледән-төрле. Көненә җиде мәртәбә ашаталар. Өстәлдә җиләк-җимеш, яшелчә. Яңа сыккан алма сулары. Барлык ризыклар да хәләл.

Лагерьда 250 бала ял итә, шуларның 113се - татарлар. Уртак спорт ярышларында катнашып, алдынгы урыннарны яулыйлар. Татар кызларының яулыктан, озын күлмәктән йөрүләренә нәфрәтле караш юк. Хезмәткәрләр татар төркеменә югары бәя бирәләр һәм үзләренең тәртиплелекләре белән аерылып торалар, диләр.

Спорт залында биш вакыт намаз укуга лагерь мөдире хөрмәт белән карый һәм мөселманча яшәүләренә соклану белдерә.

Һәр көнне татар теле, Ислам дине дәресләре. Кызлар һәм малайлар төркемнәрендә инде Изге Китабыбыз Коръәни-Кәримне укый ала торганнары бар. Һәр дүрт намазда 113 бала спорт залында намазлыкта.

**Иртәнге намаз турында тәрбияче, “Яктылык” мәктәбе мөдиренең тәрбия буенча урынбасары, Самар мөфтиятенең җәмәгатьчелек белән элемтә урнаштыру бүлеге җитәкчесе, мәгънәви яктан мөфтиятнең идеологы Радик Газизов фикере: “Без балаларны иртәнге намазга ирексезләп уятмыйбыз. Теләгәннәр, уяткыч сәгать куеп, үзләре торалар һәм тәрбиячеләр белән намаз укыйлар. Дин сабакларына да көчләү юк. Татар теле дәресләренә барлык балалар да йөри. Гаиләдә төпле тәрбия алган балалар белән эшләү җиңел. Гореф-гадәтләребез сакланмаган гаиләләрдә проблемалар күп. Педагогик белемле, тәҗрибәле укытучыларыбыз аптырап калмыйлар. Гөлфия Глушкова, Галия Тупасова, Гөлфия Ходова, Рәхимә Хәерова - үз һөнәрләренең осталары. Мәдрәсә шәкертләребез зур хезмәт куялар. Сәйфетдин хәзрәт Мөрсәлимов балаларны тыңлата да белә, тирән белем дә сеңдерә үзләренә”.**

Җәйләүдә татар теле буенча бәйге узды. Сорауларның төрледән-төрлесе яңгырады. Балалар активлык күрсәттеләр. Йорт хайваннары һәм кошлары темасына кроссворд чиштеләр. Татар теленнән урысчага тәрҗемә иттеләр, капма-каршы мәгънәле сүзләр таптылар, табышмакларны чиштеләр, бик күпләр шигырь сөйләп, бүләкләргә лаек булдылар.

Аслан Харун, Дамир Бәдәмшин, Айдар Марадуллин, Илдар Нуриев, Зөлфәт Хәеров, Сабир Галимуллин, Наилә Газизова, Аслан Нуран, Регина Тупасова, Таңсылу Сиразиева, Адилә Насыйрова, Асия Садриева - ун турда катнашып калкыган балалар. Шуларның алтысы аеруча осталыкка ия иделәр.



Укытучылар һәм тәрбиячеләр коллективы

Балаларга күпләп бүләкләр тапшырылды. Барлык чыгымнарны үз өстенә “Болгар фонды” мөдире Гомәр Мулланур углы Батыршин алды.

Бәйгене түгәрәкләп, залдагы балалар күмәк җырлар башкардылар. Атаклы “Әпипә”дән башлап заман ритмнарына кадәр.

“Иң татлы тел - туган тел, анам сөйләп торган тел” шигаре астында узган бәйгедән балалар теләмичә генә таралыштылар. Бүләккә лаек булганнар бүләкләрен карасалар, калганнары бераз көнләшеп карап тордылар. Ләкин дә барчасының йөзендә дә куаныч вә шатлык. Һәр баланың күзендә мөселман нуры балкый иде.

Кинель-Черкассы авылына кергәндә күзгә таш мәчет манарасы ташлана. Курчактай бина. Тирә-юнендә берсен-нән-берсе матур ташпулатлар. Бу - атаклы Ходовлар ыруы йортлары. Үз акчаларына урыс авылын бизәп, таш мәчет салып куйганнар. Җәйләүдәге татар балалары шул мәчеткә җомга намазына йөргәннәр. Ходовларның өлкән абыйлары Дамир татар балаларына ярдәмен күрсәтеп тора. «Ходовларның мөселманнарга күрсәткән игелекләрен санап бетергесез. Яшәүләре чын татарча. Гореф-гадәтләребезне саклап, динебез Исламга таянып эш алып баралар. Алар милләтебезнең горурлыгы һәм башкаларга үрнәк булып көн күрәләр. Шундый шәхесләр булганда, татарга хезмәт итү теләге сүнми», - ди Радик Газизов.

***Шамил БАҺАУТДИН.***

# Искәрмә

**Каникуллар вакытында балалар өчен җәйге лагерь оештырып, аларга милли тәрбия һәм гыйлем бирү мәсьәләләре Самара мөселманнарын һәм татар җәмәгатьчелеге эшлеклеләрен күптән борчый иде. Баштагы елларда бу юнәлештә төрле кыенлыклар аша үтәргә туры килде.**

**Менә быел, Аллаһыга шөкер, бу эштә шатланырлык нәтиҗәләр күренде. Әле киләчәккә тагын да матуррак планнар туа торалар. Тәрбиясезлек көчәйгән хәзерге заманда бу, әлбәттә, бик актуаль мәсьәлә. Ул - милләтне, динне саклау һәм үстерү юлындагы изге бер хәрәкәт.**

**Киләсе елда оештыралачак лагерь әле тагын да уңышлырак, нәтиҗәлерәк булсын өчен балалар һәм аларның ата-аналары белән элемтә булдыру - ул тагын да зуррак һәм җаваплырак эш. Оештыру эшләре ел әйләнәсендә һәм даими рәвештә барырга тиеш. Газетаның киләсе саннарында да без мөселман балалары өчен оештырылган лагерь эшчәнлегенә тиешле бәя бирүчеләрнең фикерләрен язачакбыз.**

**Бигрәк тә укучы балаларның, аларның ата-аналарының, укытучы-тәрбиячеләрнең, лагерь администрациясенең һәм башкаларның тәкъдимнәрен һәм теләкләрен урнаштырачакбыз.**

***РЕДАКЦИЯ.***

Халяль

**Продукты питания “Халяль” в “Космопорте”**

Халяль Магазин 1
Халяль Магазин 2
Кассы “Ашан”

**Магазин 1:** Колбасы, копчености, мясные деликатесы. Восточные сладости.

**Магазин 2:** Всегда свежее мясо - говядина, баранина, конина, индейки, куры.

Время работы: с 9.00 до 22.00, т. 8 937 655 74 84

Игътибар!
«Ислам-Нур» газетасына язылу дәвам итә.

**Аңа Самара өлкәсенең һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**

Индекс: 52381